МИНИСТЕРСТВО ЗДРАВООХРАНЕНИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

ПРИКАЗ

БОЕРЫК

28.05.2013

№ 866

Казан шәһәре

Татарстан Республикасы территориясендә халык медицинасы белән шөгыльләнүгә рөхсәт кәгазе бирү һәм халык медицинасы белән шөгыльләнү тәртибен раслау турында

2011 елның 21 ноябреннән булган 323-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә гражданнар сәламәтлеген саклау нигезләре турындагы» Федераль законның 50 маддәсе белән туры китереп, Россия Федерациясе гражданнарының халык медицинасы белән шөгыльләнергә хокукларын тормышка ашыру максаты белән һәм 2013 елның 22 февралендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 128 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы турындагы Кагыйдәләр белән туры китереп, боерам:

1. Беркетелгән Татарстан Республикасы территориясендә халык медицинасы белән шөгыльләнүгә рөхсәт кәгазен бирү һәм халык медицинасы белән шөгыльләнү тәртибен расларга.

2. Казан, Яр Чаллы шәһәре, Нижнекамск, Әлмәт муниципаль районнары буенча Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы сәламәтлек саклау идарәсе башлыкларына, үзәк район хастаханәләре баш табибларына карамакта булган медицина оешмаларында халык медицинасы ысулларын кулланган вакытта катгый Татарстан Республикасы территориясендә халык медицинасы белән шөгыльләнүгә рөхсәт кәгазен бирү һәм халык медицинасы белән шөгыльләнү тәртибе буенча эш итәргә.

3. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының юридик бүлеге башлыгы Т.А. Стрюковага кабул ителгән тәртиптә шушы боерыкның дәүләт теркәлүен һәм рәсми нәшер ителүен тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы Бухгалтерлык исәбе һәм хисабы идарәсе башлыгы вазыйфаларын башкаручы М.М.Маркичевага шушы боерыкны рәсми нәшер итү чыгымнарын түләүне тәэмин итәргә.

5. Халык медицинасы белән шөгыльләнүгә рөхсәт кәгазьләрен бирү буенча эшләрне оештыруга җаваплылыкны Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы Лицензирование буенча идарәгә тапшырырга.

6. «Татарстан Республикасы территориясендә халык медицинасы белән шөгыльләнү (дәвалау белән шөгыльләнү) һәм дәвалаучы дипломын бирү тәртибен раслау турындагы» Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының 10.12.2010нан булган 1562 номерлы боерыгын;

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының 10.12.2010нан булган 1562 номерлы боерыгына үзгәртүләр кертү турындагы» Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының 05.05.2011дән булган 607 номерлы боерыгын көчен югалткан дип танырга.

7. Шушы боерыкның үтәлүен тикшерүне Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы урынбасары Р.С. Җәләлетдиновка тапшырырга.

Министр А.З.Фәррахов

23.04.2012 елдагы 572 номерлы
Татарстан Республикасы сәламәтлек
саклау министрлыгының боерыгы белән
расланган

**Татарстан Республикасы территориясендә халык медицинасы белән шөгыльләнүгә рөхсәт бирү һәм халык медицинасы белән шөгыльләнү тәртибе**

## I. Гомуми фикерләр

1. Бу Тәртип халык медицинасы белән шөгыльләнүгә гражданнар хокукларын тормышка ашыру белән бәйле барлыкка килгән оештыру-хокукый мөнәсәбәтләрне тәртипкә сала, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә халык медицинасы белән шөгыльләнүгә рөхсәт кәгазен бирү, яңадан рәсмиләштерү һәм рөхсәт кәгазеннән мәхрүм итү тәртибен урнаштыра.

2. Бу Тәртипнең максатлары:

халык медицинасы белән шөгыльләнә торган гражданнар хокукын саклау, халык медицинасы белән шөгыльләнә торган шәхесләр хезмәтләре белән файдаланган кулланучылар хокукын саклау, шулай ук Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы (түбәндә – Министрлык), профессиональ медицина ассоциацияләре, медицина оешмаларының закончылык белән билгеләнгән вәкаләтләрен тормышка ашыру;

халык медицинасы өлкәсендә хезмәтләрнең сыйфатын күтәрүне һәм хәвефсезлеген тәэмин итү;

хәзерге һәм халык медицинасының интеграцияләү барышын тирәнәйтүгә булыша торган хокук нормаларын һәм чараларын урнаштыру, практик сәламәтлек саклавына халык медицинасы алымнарын һәм чараларын кертү, халык медицинасы өлкәсендә эшләүче оешмалар һәм белгечләр эшчәнлеген координацияләү.

## II. Төп төшенчәләр

3. **Халык медицинасы** – бу сәламәтлекне билгеләү һәм төзәтү буенча белемнәр, сәләтләр һәм практик осталыклар белән файдалану нигезендә ята торган халык тәҗрибәсендә расланган сәламәтләндерү алымнары.

4. **Халык медицинасы өлкәсендәге белгеч** – Министрлык белән бирелгән халык медицинасы белән шөгыльләнүгә рөхсәт кәгазе булган, медицина профессиональ коммерцияле булмаган оешманың язма гаризасы белән расланган, халык медицинасы өлкәсендә профессиональ белемнәргә һәм практик эшчәнлекнең тәҗрибәсенә ия булган Россия Федерациясенең гражданины.

5. **Халык медицинасы белән шөгыльләнүгә рөхсәт кәгазе** – аны кулда тотучыга халык медицинасы өлкәсендәге белгеч статусын билгели торган һәм аңа халык медицинасы белән шөгыльләнүгә хокук бирә торган документ.

6. **Медицина профессиональ коммерцияле булмаган оешманың язма гаризасы** – халык медицинасы белән шөгыльләнүгә рөхсәт кәгазен бирү өчен нигез булган, рөхсәт кәгазен алырга теләүче файдалана торган, сыйфат һәм хәвефсезлек критерийләренә туры килгән халык медицинасы алымнарын тану турында традицион һәм халык медицинасы белгечләренең Россия профессиональ медицина ассоциациясенең рәсми нәтиҗәсе.

7. **Халык медицинасы белән шөгыльләнүгә рөхсәт кәгазен алырга теләүче** – халык медицинасы белән шөгыльләнүгә рөхсәт кәгазен бирү турындагы гариза белән Министрлыкка мөрәҗәгать иткән Россия Федерациясенең гражданины.

## III. Халык медицинасы белән шөгыльләнүгә рөхсәт кәгазен алуның, яңадан рәсмиләштерүнең һәм мәхрүм итүнең тәртибе

8. Халык медицинасы белән шөгыльләнүгә рөхсәт кәгазен алыр өчен рөхсәт кәгазен алырга теләүче Министрлыкка теркәлгән форма буенча (1 номерлы кушымта) халык медицинасы белән шөгыльләнүгә рөхсәт кәгазен бирү турында гариза тапшыра.

9. Халык медицинасы белән шөгыльләнүгә рөхсәт кәгазен бирү турындагы гаризага түбәндәгеләр теркәлә:

- традицион һәм халык медицинасы белгечләренең Россия профессиональ медицина ассоциясенең язма гаризасының күчермәсе;
- профессиональ (медицина) белемен раслый торган документлар күчермәсе - булган очракта;
- медицина эшчәнлеген тормышка ашыруга лицензиянең күчермәсе - булган очракта.

10. Халык медицинасы белән шөгыльләнүгә рөхсәт кәгазен алырга теләүчедән бу Тәртип белән исәпкә алынмаган документлар тапшыруны таләп итүгә юл куелмый.

11.Халык медицинасы белән шөгыльләнүгә рөхсәт кәгазен бирү турындагы гаризаны карау һәм халык медицинасы белән шөгыльләнүгә рөхсәт кәгазен бирү яисә бирүне кире кагу турындагы карар гариза һәм аңа теркәлгән документлар алынганнан соң 30 көннән артык булмаган вакыт эчендә кабул ителә. Күрсәтелгән карар Министрлык боерыгы белән рәсмиләштерелә.

12.Халык медицинасы белән шөгыльләнүгә рөхсәт кәгазен алырга теләүче 11нче пунктта күрсәтелгән вакыт эчендә халык медицинасы белән шөгыльләнүгә рөхсәт кәгазен бирү яисә бирүне кире кагу турындагы карарны кабул итү турында хәбәр ителә (кире кагуның сәбәбен күрсәтеп). Хәбәр кәгазе рөхсәт кәгазен алырга теләүчегә язма формада җибәрелә (бирелә).

13.Халык медицинасы белән шөгыльләнүгә рөхсәт кәгазе теркәлгән формада (2 номерлы кушымта) 5 елга бирелә.

14.Халык медицинасы белән шөгыльләнүгә рөхсәт кәгазен бирүне кире кагу турындагы карарны кабул итү өчен нигез булып:

халык медицинасы белән шөгыльләнүгә рөхсәт кәгазен рөхсәт кәгазен алырга

теләүченең традицион һәм халык медицинасы белгечләренең Россия профессиональ медицина ассоциациясенең язма гаризасы күчермәсен бирмәве яисә традицион һәм халык медицинасы белгечләренең Россия профессиональ медицина ассоциациясенең язма гаризасын тискәре бирүе;

рөхсәт кәгазен алырга теләүче тәкъдим иткән гаризада һәм (яисә) документларда дөрес булмаган яки бозып күрсәтелгән мәгълүмат барлыгы;

рөхсәт кәгазен алырга теләүче белдергән сәламәтләндерү ысулларының законнылык белән кабул ителгән халык медицинасы билгеләренә туры килмәве тора.

15.Халык медицинасы белән шөгыльләнүгә рөхсәт кәгазен алырга теләүче халык медицинасы белән шөгыльләнүгә рөхсәт кәгазен бирүне кире кагуга Россия Федерациясе законнылыгы белән кабул ителгән тәртиптә шикаять бирергә хокуклы.

16.Югалткан очракта, рөхсәт кәгазенең иясе күрсәтелгән документның бирелгән форма (3 номерлы кушымта) буенча язылган гариза нигезендә бирелә торган дубликатны алырга хокуклы.

17.Халык медицинасы белән шөгыльләнүгә рөхсәт кәгазенең гамәлдә булу вакыты беткәч халык медицинасы өлкәсендәге белгечләр шушы Тәртипнең 8-12 пунктларына туры китереп халык медицинасы белән шөгыльләнүгә яңа рөхсәт кәгазен алалар.

18.Исем яки яшәү урыны үзгәргән, шулай ук халык медицинасы өлкәсендәге эшчәнлекне тормышка ашыру урынының адресы үзгәргән очракта халык медицинасы өлкәсендәге белгеч халык медицинасы белән шөгыльләнүгә рөхсәт кәгазен яңадан рәсмиләштерү турында гариза бирергә тиеш. Гаризада халык медицинасы өлкәсендәге белгеч турында яңа мәгълүматлар һәм бердәм дәүләт шәхси эшмәкәрләр исемлегенә тиешле үзгәртүләр кертү фактын раслаучы документта күрсәтелгән мәгълүматлар күрсәтелә. Бердәм дәүләт шәхси эшмәкәрләр исемлегенә үзгәртүләр керткәч яки халык медицинасы өлкәсендәге эшчәнлекне тормышка ашыру урынының адресы, исем, яшәү урыны үзгәргәч унбиш көннән дә соңга калмыйча халык медицинасы белән шөгыльләнүгә рөхсәт кәгазен яңадан рәсмиләштерү турындагы гариза халык медицинасы өлкәсендәге белгеч белән Министрлыкка тапшырыла.

19.Халык медицинасы белән шөгыльләнүгә рөхсәт кәгазен яңадан рәсмиләштерү тиешле гаризаны алганнан соң ун көн эчендә башкарыла. Күрсәтелгән вакытта халык медицинасы белән шөгыльләнүгә рөхсәт кәгазен яңадан рәсмиләштерү яки яңадан рәсмиләштерүне кире кагу турында карар кабул итү турында белдерелә. Белдерү кәгазе халык медицинасы өлкәсендәге белгечкә язма формада юнәлдерелә (тапшырыла).

20.Халык медицинасы белән шөгыльләнүгә рөхсәт кәгазен яңадан рәсмиләштерүне кире кагу турындагы карарлар өчен нигез булып халык медицинасы өлкәсендәге белгечнең тулы булмаган яки дөрес булмаган мәгълүматлар тапшыруы тора. Халык медицинасы белән шөгыльләнүгә рөхсәт кәгазен яңадан рәсмиләштерүне

кире кагу турындагы белдерү кәгазе халык медицинасы өлкәсендәге белгечкә кире кагу сәбәпләрен күрсәтеп язма формада юнәлдерелә (тапшырыла).

21. Халык медицинасы белән шөгыльләнүгә рөхсәт кәгазеннән мәхрүм итү Министрлык карары белән башкарыла. Халык медицинасы белән шөгыльләнүгә рөхсәт кәгазеннән мәхрүм итү өчен нигез булып:

- халык медицинасы өлкәсендәге белгечнең сәламәтлек саклау өлкәсендәге законнарлыкның, реклама турындагы, кулланучылар хокукларын саклау турындагы законнарлыкның кабул ителгән таләпләрен, халык медицинасы белән шөгыльләнү тәртибенә куелган таләпләрне бозуы;
- халык медицинасы өлкәсендәге белгечнең эшчәнлеген тыю турындагы суд карарының законлы көчкә керүе торалар.

22. Халык медицинасы белән шөгыльләнүгә рөхсәт кәгазен бирү турындагы гаризаны кабат тапшыру халык медицинасы белән шөгыльләнүгә рөхсәт кәгазеннән мәхрүм итү турындагы карарны кабул иткәннән соң ике елдан да иртәрәк мөмкин түгел.

23. Вакытыннан элек халык медицинасы белән шөгыльләнүгә рөхсәт кәгазенең көче бирелгән форма буенча Министрлыкка тапшырылган халык медицинасы белән шөгыльләнүгә рөхсәт кәгазен гамәлдән чыгару турындагы гариза нигезендә дә бетә (5 номерлы кушымта).

## IV. Халык медицинасы өлкәсендә эшчәнлек алып бару тәртибе

24. Татарстан Республикасы территориясендә халык медицинасы белән шөгыльләнергә халык медицинасы өлкәсендә профессиональ коммерцияле булмаган оешмаларның язма гаризасы белән расланган профессиональ белемнәре һәм практик эшчәнлек тәҗрибәсе, Министрлык биргән халык медицинасы белән шөгыльләнүгә рөхсәт кәгазе булган кешеләргә рөхсәт ителә.

25. Медицина белеме булмаган халык медицинасы өлкәсендәге белгеч халык медицинасы өлкәсендәге эшчәнлекне табиб тикшерүе астында (медицина оешмалары белән, хосусый медицина практикасы белән шөгыльләнүче табиблар белән килешүләр нигезендә) алып бара.

26. Халык медицинасы өлкәсендәге белгеч халык медицинасы өлкәсендә эшчәнлек алып барганда бары тик халык медицинасы белән шөгыльләнүгә рөхсәт кәгазендә күрсәтелгән ысулларны гына кулланырга хаклы.

27. Халык медицинасы өлкәсендәге эшчәнлекне алып барганда халык медицинасы өлкәсендәге белгеч:

- үз белемнәрен һәм осталыкларын гражданнарның тормышына һәм/яки сәламәтлекләренә зарар китерү өчен файдаланмаска;
- сәламәтлек саклау сферасындагы законнар белән кабул ителгән медицинаның исәп һәм хисап документларын алып барырга;
- ярдәм күрсәткәндә кабул ителгән тәртиптә рөхсәт ителгән әсбаплар һәм җайланмалар белән кулланырга;

- гражданнарны кулланучыларның хокукын саклау турындагы закончылык белән каралган аларга күрсәтелә торган хезмәтләр турында ала алырдай һәм ышанычлы мәгълүмат белән тәэмин итәргә;
- сәләтләренең һәм квалификациянең халык медицинасы өлкәсендәге эшчәнлекне алып бару хокукын алуның профессиональ критерияләренә туры килүен һәр биш ел традицион һәм халык медицинасы белгечләренең Россия профессиональ медицина ассоциациясенә әгъзаларга;
- үз эшчәнлеген Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы закончылыгы белән, шулай ук шушы Тәртиптә кабул ителгән таләпләр белән туры китереп үтәргә тиеш.

28.Халык медицинасы өлкәсендәге эшчәнлек санитария кагыйдәләренә, янгын иминлеге таләпләренә, төзү нормалары һәм кагыйдәләренә туры килүче биналарда (корылмалар, бүлмәләрдә) алып барыла.

29.Халык медицинасы өлкәсендәге белгечләргә, массакүләм мәгълүмат чаралары куллану белән үткәрүләрне кертеп, массакүләм дәвалау белән шөгыльләнү сеанслары үткәрү тыела.

30.Россия Федерациясенең башка субъектларының сәламәтлек саклау сферасындагы башкарма хакимият әгъзалары биргән халык медицинасы белән шөгыльләнүгә рөхсәт кәгазе Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә түгел.

Халык медицинасы белән шөгыльләнү
һәм Татарстан Республикасы территориясендә халык
медицинасы белән шөгыльләнүгә рөхсәт кәгазен бирү тәртибенә
1нче номерлы кушымта

Теркәлү номеры ________
«___»____________20___ел.

Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау министрлыгына
420111, Казан, Островский ур., 11/6

**Халык медицинасы белән шөгыльләнүгә рөхсәт кәгазен бирү турында гариза**

Гариза бирүче: ________________________________________________
фамилия, исем, әтисенең исеме

Яшәү урыны: __________________________________________________
______________________________________________________________

Шәхесне раслаучы документта күрсәтелгән мәгълүматлар: _______________
______________________________________________________________
документның төре, сериясе, номеры, бирелү датасы, кем биргән

Халык медицинасы өлкәсендәге эшчәнлекне тормышка ашыру урынының адресы:
______________________________________________________________
______________________________________________________________

Телефон ________________Факс _________________E-mail___________________
ОГРНИП _____________________________ИНН__________________________

2011 елның 21 ноябреннән булган «Россия Федерациясе гражданнарының сәламәтлекләрен саклау нигезләре турындагы» 323-ФЗ номерлы Федераль законның 50нче маддәсе 3нче пункты белән туры китереп халык медицинасының түбәндәге ысуллары буенча ________________________________________________
______________________________________________________________
______________________________________________________________
медицина профессиональ коммерцияле булмаган оешмаларның язма гаризасы
белән туры китереп халык медицинасының ысуллары

халык медицинасы белән шөгыльләнүгә рөхсәт кәгазен бирүегезне үтенәм.

Тәкъдим ителгән документларның дөреслеген раслыйм. Халык медицинасы өлкәсендәге эшчәнлекне алып барганда сәламәтлек саклау сферасындагы Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнылыгын, Татарстан Республикасы территориясендә халык медицинасы белән шөгыльләнүгә рөхсәт кәгазен бирү һәм халык медицинасы белән шөгыльләнү тәртибен үтәргә вәгъдә итәм.

Кушымталар:

1. Медицина профессиональ коммерцияле булмаган оешманың язма гаризасы.
2. Профессиональ (медицина) белемен раслаучы документларның күчермәләре (булган очракта).
3. Медицина эшчәнлеге үтәү лицензиясенең күчермәсе (булган очракта).

Гариза бирүче ________________ ____________________________

имза инициаллар, фамилия

“___” ________________ 20___ ел

П.У.

Халык медицинасы белән шөгыльләнү
һәм Татарстан Республикасы территориясендә халык
медицинасы белән шөгыльләнүгә рөхсәт кәгазен бирү тәртибенә
2нче номерлы кушымта

Татарстан Республикасының
Дәүләт гербы сүрәте

ТР сериясе 000000

Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау министрлыгы

**Татарстан Республикасы территориясендә халык медицинасы белән шөгыльләнүгә рөхсәт кәгазе**

N_____ 20___елның "___"________ ннән

Халык медицинасы белән шөгыльләнүгә рөхсәт кәгазе
20________ел____________дән булган___________номерлы традицион һәм халык медицинасы белгечләренең Россия профессиональ медицина ассоциациясенең рөхсәт кәгазенә язма гаризасы нигезендә ____________________________________________

______________________________________________________________

(фамилия, исем, әтисенең исеме)

бирелгән.

Шәхесне раслаучы документ:___________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

(документ төре, сериясе, номеры, бирелү датасы, кем биргән)

ОГРНИП ______________________________ ИНН ______________________________

Яшәү урыны:_______________________________________________________

______________________________________________________________

Халык медицинасы өлкәсендәге эшчәнлекне тормышка ашыру урынының адресы:

______________________________________________________________

Татарстан Республикасы территориясендә рөхсәт ителгән халык медицинасы алымнары: _______________________________________________________

______________________________________________________________

(рөхсәт бирүгә язма гариза белән туры килгән халык медицинасы алымнары исемлеге)

Эшчәнлекнең шушы төрен башкару шартлары:_____________________________

______________________________________________________________

(мөстәкыйль, табиб тикшерүе астында)

Шушы рөхсәт кәгазенең гамәлдә булу вакыты:___________________________ дән
__________________________кадәр

______________________________ ______________________________ ______________________________

(вәкаләтле шәхес вазифасы) (имза) (инициаллар, фамилия)

П.У.

Халык медицинасы белән шөгыльләнү
һәм Татарстан Республикасы территориясендә халык
медицинасы белән шөгыльләнүгә рөхсәт кәгазе бирү тәртибенә
3нче номерлы кушымта

Теркәлү номеры ___________
«___»_____________20___ел.

Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау министрлыгына
420111, Казан, Островский ур., 11/6

**Халык медицинасы белән шөгыльләнүгә**
**рөхсәт кәгазенең дубликатын бирү турында**
**гариза**

Гариза бирүче: ____________________________________________________
фамилия, исем, әтисенең исеме

Яшәү урыны: ______________________________________________________
__________________________________________________________________

Шәхесне раслаучы документта күрсәтелгән мәгълүматлар: ________________
__________________________________________________________________
документның төре, сериясе, номеры, бирелү датасы, кем биргән

Халык медицинасы өлкәсендәге эшчәнлекне тормышка ашыру урынының адресы:
__________________________________________________________________
__________________________________________________________________

Телефон_______________Факс _______________E-mail___________________
ОГРНИП ____________________________ИНН__________________________

"___"__________20___елга кадәр гамәлдә булу вакыты белән ___.___20___елдан бирелгән __________ номерлы халык медицинасы белән шөгыльләнүгә рөхсәт кәгазен югалту белән бәйле аның дубликатын бирүегезне үтенәм

Гариза бирүче _______________ _______________________
имза инициаллар, фамилия

"___"______________20___ ел

П.У.

Халык медицинасы белән шөгыльләнү
һәм Татарстан Республикасы территориясендә халык
медицинасы белән шөгыльләнүгә рөхсәт кәгазен бирү тәртибенә
4нче номерлы кушымта

Теркәлү номеры __________
«___»______________20___ел.

Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау министрлыгына
420111, Казан, Островский ур., 11/6

**Халык медицинасы белән шөгыльләнүгә**
**рөхсәт кәгазен яңадан рәсмиләштерү турында**
**гариза**

Гариза бирүче: ____________________________________________________________
фамилия, исем, әтисенең исеме

Яшәү урыны: ______________________________________________________________
__________________________________________________________________________

Шәхесне раслаучы документта күрсәтелгән мәгълүматлар: _______________________
__________________________________________________________________________
документның төре, сериясе, номеры, бирелү датасы, кем биргән

Халык медицинасы өлкәсендәге эшчәнлекне тормышка ашыру урынының адресы:
__________________________________________________________________________
__________________________________________________________________________

Телефон ___________________ Факс ___________________E-mail___________________
ОГРНИП ______________________________________ИНН____________________________

“___”______________20___елга кадәр гамәлдә булу вакыты белән ___.___20___елдан бирелгән _____________ номерлы халык медицинасы белән шөгыльләнүгә рөхсәт кәгазен ____________________________________________________________
__________________________________________________________________________
халык медицинасы белән шөгыльләнүгә рөхсәт кәгазен яңадан рәсмиләштерүгә нигез
белән бәйле яңадан рәсмиләштерүегезне үтенәм

Тәкъдим ителгән документларның дөреслеген раслыйм. Халык медицинасы өлкәсендәге эшчәнлекне алып барганда сәламәтлек саклау сферасындагы Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасы территориясендә халык медицинасы белән шөгыльләнүгә рөхсәт кәгазен бирү һәм халык медицинасы белән шөгыльләнү тәртибен үтәргә вәгъдә итәм.

Гариза бирүче

_______________ имза

_______________ инициаллар, фамилия

“___”______________20___ ел

П.У.

Халык медицинасы белән шөгыльләнү
һәм Татарстан Республикасы территориясендә халык
медицинасы белән шөгыльләнүгә рөхсәт кәгазен бирү тәртибенә
5нче номерлы кушымта

Теркәлү номеры __________
«___»______________20___ел.

Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау министрлыгына
420111, Казан, Островский ур., 11/6

**Халык медицинасы белән шөгыльләнүгә**
**рөхсәт кәгазен гамәлдән чыгару турында**
**гариза**

Гариза бирүче: ______________________________________________
фамилия, исем, әтисенең исеме

Яшәү урыны: ______________________________________________
______________________________________________________

Шәхесне раслаучы документта күрсәтелгән мәгълүматлар: ________________
______________________________________________________
документның төре, сериясе, номеры, бирелү датасы, кем биргән

Халык медицинасы өлкәсендәге эшчәнлекне тормышка ашыру урынының адресы:
______________________________________________________
______________________________________________________

Телефон __________________Факс _________________E-mail____________________
ОГРНИП ______________________________ИНН______________________________

Халык медицинасы өлкәсендәге эшчәнлекне туктату белән бәйле
“___”______________ ___елга кадәр гамәлдә булу вакыты белән ___.___20___елдан
бирелгән ______________ номерлы халык медицинасы белән шөгыльләнүгә рөхсәт
кәгазен гамәлдән чыгаруыгызны үтенәм.

Гариза бирүче ______________ ______________
имза инициаллар, фамилия

“___”______________20___ ел

П.У.